***Кадирова Э.Х.***
*К.ф.н., доцент КФУ,*
***Кадирова Д.М.***
*аспирант ИЯЛИ АН РТ*
*Республика Татарстан; г.Казань.*

# Хуҗа Бәдигый татар әдәби теле тарихы мәсьәләләре хакында

Хуҗа Бәдигый – татар тел белеме өлкәсендә тирән эз калдырган күренекле галим. Ул, олуг галимнәребезнең эшен дәвам итеп, татар тел белеменә төрле өлкәләрендә бәрәкәтле фәнни мирас калдыра. Галимнең татар әдәби теле һәм тел белеме тарихын өйрәнү, алфавит һәм орфографияне камилләштерү, фәнни терминология нигезләрен эшкәртү, татар теленең лексик байлыгын, морфологик һәм синтаксик төзелешен өйрәнү һәм методика өлкәләренә караган хезмәтләре ул хезмәт иткән елларда татар тел белеменең торышын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Х. Бәдигыйнең фәнни мирасы шактый бай булуга карамастан, аның хезмәтләре бүгенге көнгә кадәр бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән генә түгел, аларның күбесе әле бастырылып та чыгарылмаган. Алар хәзерге вакытта ТР ФА нең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәгендә  (Т.19) саклана [Әхмәтҗанов, 2005:165-166].  Бу хезмәтләр тематик яктан тел белеменең төрле тармакларына карый. Анда, мәсәлән, Х. Бәдигыйнең гомуми тел белеме, фонетика, грамматика, лексикология, стилистика өлкәләренә караган, басылып чыкмаган кульязмалары саклана.

Х. Бәдигыйнең татар әдәби теленең үсеше, аның чорларга бүленеше, һәр чорда аңа хас үзенчәлекләр кебек мәсьәләләргә багышланган хезмәтләре дә бар. 1930 елда авторның “Безнең юл” журналында “Татар әдәби теленең барышы” мәкаләсе басылып чыга. Ул анда “татар әдәби теленең формалашу юлын дөрес билгели, ничек формалашуын дөрес ача” [Зәкиев, 2008:13]. Әлеге һәм 1932 елда “Яңалиф” журналының 9-10 санында басылган “XV ел

эчендә татар әдәби теле" мәкаләләрендә Х.Бәдигый шулай ук татар әдәби теленең үсешендә соңгы елларда иске мирас белән беррәттән яңа сүзләр аша телне баетуны ачык күрә һәм аның юлларын күрсәтә. Галим 1931 елда читтән торып уку курслары өчен "Татар теле грамматикасы" дәреслеген бастырып чыга. Китапта автор төп темалар эченә татар әдәби теленең фонетикасы, морфологиясе, синтаксисын өйрәнә башлаганчы, кереш өлешендә "Телнең иҗтимагый тормышта роле һәм аны өйрәнүнең методологиясе", "Тел һәм уй", "Телләрнең системалары", "Татар әдәби теле һәм аның дәверләре", "Тел белеме һәм аның бүлекләре" дип исемләнгән параграфлар астында гомуми тел белеме проблемаларына да туктала. "Татар әдәби теле һәм аның дәверләре" бүлегендә галим әдәби тел, җирле тел терминына аңлатма бирә: "Болар һәр икәве бер үк халыкның, бер үк тел коллективының телләре булсалар да, ләкин һәр хәлдә алар арасына тигезлек билгесе куярга мөмкин түгел. Халык теле – чуар тел. Ул үз эчендә төрле диалектларга, диалектлар тагын үз нәүбәтендә әйтешләргә (говорларга) аерыла. Җирле халык, гадәттә, үзара үзләренең җирле телләре белән, җирле диалект, җирле әйтеш телләре белән аңлашалар. Җирле тел – җирле халыкның ихтыяҗларын гына үти ала. Бер әдәби тел эченә кергән шул ук җирле халык матбугат мәйданына чыгып, берәр хәбәр, мәкалә, әсәр язарга теләсә, ул инде бөтен тел коллективы өчен уртак булган әдәби тел белән генә яза" [Бәдигый, 1931:9]. Х.Бәдигый татар әдәби теленең үсү процессын 3 чорга бүлеп карый:

1) феодализм дәверендәге әдәби тел;

2) буржуачылык – милләтчелек дәверендәге әдәби тел;

3) Октябрь революциясеннән соңгы әдәби тел [Бәдигый, 1931:10-13].

Бу бүленеш галимнең 1930 елда "Безнең юл" журналының икенче һәм өченче саннарында басылган "Татар әдәби теленең барышы" мәкаләсендә дә урын ала.

Автор беренче чорны Көнбатыш Европа әдәби телләрендә XV-XVI, рус әдәби телендә XVIII йөзгә кадәр булган вакыт белән тиңли. Аныңча, татар

әдәби телендә бу чор кыпчак-угыз әдәби теленнән аерылып чыкканнан алып XIX йөзнең соңгы яртысына кадәр сузыла [Бәдигый, 1931:12]. Татар әдәби теленең икенче чорына характеристика биреп, галим болай дип яза: Аның җирлеге кыпчак угыз әдәби теле булган хәлдә, анда бер яктан чыгтай, икенче яктан бераз соңрак анатолий төрек әдәби телләренең йогынтылары бар иде. Шулай да ул кыпчак әдәби теле дә түгел иде бәлки үзенә аерым шул алган татар әдәби теле иде [Бәдигый, 1931:12].

Казан федераль университетының кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Х.Бәдигыйнең 1935 нче елда тел экспедициясе материаллары буенча төзелгән башлангыч йомгаклар “Хәзерге татар әдәби һәм сөйләү теленең лексика-семантика ягыннан үсеш тенденциясе” хезмәте саклана. Анда да татар әдәби теленең үсеше юнәлешендә аерым нәтиҗәләр ясала. Бу турыда галим үзенең “Доцент Бәдигов Х.Б.ның фәнни-тикшеренү сызыгы буенча исемлегендә дә искә ала: “ Бу йомгакларда әдәби тел төшенчәсе, татар әдби теленең үсеш этаплары, телдә сүзлек составы һәм аның социаль-экономик максатларга карап үзгәрүчәнлеге, Октябрьдән соң татар эшчеләре һәм колхозчылары сөйләү теленең әдәби тел белән бергә үсеше, аның бу үсешендә интернациональ юнәлешлелеге һ.б. турында фактик тел материалларыннан чыгып анализ ясала [Бәдигый фонды (№19), тасв. 1, сак. бер.5]. Х.Бәдигый хезмәттә, татар әдәби теле үсешенең бүленешенә нигезләнеп, һәр чорда, бигрәк тә Октябрь революциясеннән соңгы елларда татар әдәби теленең эчтәлегенә игътибар итә. Ул татар әдәби теленең үсүе өчен шартлар тууда Октябрь революциясенең әһәмияте зур булуын билгели. Октябрь революциясеннән соң җәмгыятнең төзелеше үзгәрү белән бергә әдәби телнең төзелеше дә үзгәрә, ә телдәге бу үзгәреш һәммәсеннән элек аның сүзлек составында ачыграк чагыла. Октябрь революциясеннән соң әдәби тел сүзлек составының үсүе электәге сүзләрнең мәгънәләре үзгәрү, киңәю яки конкретлашу белән генә чикләнми, яңа төшенчәләрне аңлату өчен аның күләме дә сан һәм сыйфат ягыннан бик нык үзгәрә, үсә.

“Үзләрендә патшалык төзелешен чагылдырган старшина, урәдник, губернатор, патша, әфәндем хәзрәтләре кебек бик күп сүзләр, терминнар хәзер архивка ташландылар, совет, съезд, председатель, секретарь Әдәби телнең сүзлек составы кайбер сүзләрнең туулары белән генә үзгәреп калмый, бәлки бу үзгәреш элек тә кулланылып килгән кайбер сүзләрнең мәгънәләрендә һәм кулланылу функцияләрендә дә чагылырга мөмкин” дип билгели галим һәм үз фикерен мисаллар белән раслый. Мәсәлән, йомгак (җеп йомгагы) – сөйләнгән фикернең йомгагы, кадак (дага кадагы – көннең кадагы), баскыч (агач баскыч, беренче баскыч) һ.б. Мәгънәләре киңәйгән сүзләргә фронт (сугыш фронты, культура фронты), көрәш (батырлар көрәше, социализм өчен көрәш), өзеклек (йул өзеклеге – производство өзеклеге) һ.б. керә.

Хезмәттә автор “Вакыт” һәм “Йолдыз” газеталары мисалында бу чорда татар матбугаты телендә алынмаларның кулланылыш үзенчәлекләрен барлый. Ул, төп кимчелек итеп, газеталарда гарәп-фарсы алынмаларының кирәктән артык урын алуын күрсәтә. Х.Бәдигый әлеге газеталарга янәшә “Урал” газетасын куя һәм анда татарның үз сүзләре 48 – 49 % урынына 72,2 %, ә гарәп-фарсы алынмаларының 19,5 % икәнлеген ассызыклый, рус алынмаларының да артыграк булуын күрсәтә. Ул татар халкына якын, аңлаешлы итеп язарга тырышу юнәлешендә “Урал” газетасын мисалга китерә. Әмма “Урал” газетасы 30 гына номер чыгып кала. Галим төрек теле алынмаларына да үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Ул телебез “төрек сүзләре белән чуарланды,” – ди һәм мисаллар китерә: чочык – бала, чук – күп, таләп кыла – таләп итә һ.б.

Бу чорда төрле өлкәләргә караган терминнар арасында да гарәп-фарсы алынмалары күпчелекне алып тора, татар халкына бөтенләй ят сүзләр, гыйбарәләр өстенлек итә, хәтта интернациональ терминнар да гарәпчә формалаштырылганнар. Галим татар терминологиясен камилләштерү юлында өч чыганакны билгели: хәзерге татар әдәби һәм сөйләү теле; интернациональ терминнар; хәзерге рус әдәби теле терминнары [Бәдигый,

1935:17]. Х.Бәдигый татар теленең үз сүзлек байлыгыннан файдалануны кулай күрә һәм татар телендә уңышлы вариант булмаган очракта рус теленә, рус теле аша кергән халыкара сүзләргә мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә; татар теленең үз грамматик чараларыннан файдаланып терминнар ясауны хуплый.

Шул рәвешле, Х.Бәдигыйнең татар әдәби теленең тарихын өйрәнүдә үз урыны бар.

Файдаланылган әдәбият


1. Әхмәтҗанов М.И. Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. – Казан, 2005. – 224 б.
2. Бәдигый Х. Татар әдәби теленең барышы. – Безнең юл, 1930. – №2. – С. 34-40.
3. Бәдигый Х. Татар әдәби теленең барышы. – Безнең юл, 1930. –№3-4. – С. 38-41.
4. Бәдигъ Х. Татар теле грамматикасы дәреслеге. – Казан: Татаиздат, 1931. – 37 б.
5. Бәдигъ Х. XV ел эчендә татар әдәби теле. – Яңалиф, 1932. – № 9-10. – С. 84-94.
6. Бәдигъ Х. Хәзерге татар әдәби һәм сөйләү теленең лексика-семантика ягыннан үсеш тенденциясе (1935 нче елда тел экспедициясе материаллары буенча төзелгән башлангыч йомгаклар) .
7. Зәкиев М.З. Татар тел гыйлеме үсешендә Хуҗа Бәдигый// Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог: фәнни мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 7-20 б.
8. Хаҗиева Г.С. “Татар теле грамматикасы дәресләре”ндә күтәрелгән кайбер мәсьәләләр// Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог: фәнни мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 64-69 б.